КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 1 ноябрь г.Казань № 1393

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре» 2018 ел, 12 июль, 565 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре» 2018 ел, 12 июль, 565 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 13 март, 179 нчы; 2019 ел, 18 сентябрь, 846 нчы; 2020 ел, 28 февраль, 153 нче; 2020 ел, 25 август, 734 нче; 2020 ел, 22 декабрь, 1172 нче; 2021 ел, 26 июль, 649 нчы; 2021 ел, 7 декабрь, 1182 нче; 2022 ел, 28 февраль, 180 нчы; 2022 ел, 13 май, 439 нчы; 2022 ел, 19 сентябрь, 1016 нчы; 2022 ел, 24 октябрь, 1134 нче; 2023 ел, 21 март, 300 нче; 2023 ел, 25 июнь, 752 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты турында» 2018 елның 22 июнендәге ПУ-462 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасы һәм структурасы турында» 2023 елның 4 маендагы 276 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

6 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

9 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

«*» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«*Код билгеләнеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2023 ел, 26 июнь, 752 нче карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт идарәсе функцияләре кодификаторы буенча.»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Комитет үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.07);

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән мәдәният (шул исәптән сәнгать, кинематография, тарихи-мәдәни мирасны саклау һәм файдалану) өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салу, төрле диннәрнең дини берләшмәләре арасында үзара аңлашуны һәм сабырлыкны ныгытуга ярдәм күрсәтү функциясен гамәлгә ашырганда (04.03);

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән фәнни һәм фәнни-техник эшчәнлек белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.12);

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

гражданнар оборонасы өлкәсендә чаралар оештыру һәм үткәрү белән идарә итү (02.01.01);

Татарстан Республикасының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү белән идарә итү (02.01.03);

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы белән ихтыярилар (волонтерлык) эшчәнлеге өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салу функциясен гамәлгә ашырганда (01.16);

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән социаль-икътисадый хезмәттәшлек мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары белән Россия Федерациясе субъектларындагы башкарма хакимият органнары хезмәттәшлеген тәэмин итү функциясен гамәлгә ашырганда (03.07);

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

архитектура эшчәнлеге белән идарә итү (01.04);

территориаль планлаштыру (01.05.01);

җирле үзидарә органнары тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарның үтәлешен контрольдә тоту (01.05.02);

объектларны төзү, капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү белән идарә итү

(01.05.03);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән хезмәт белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.13);

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән дәүләт финанслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.02);

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системаларын үстерү белән идарә итү (дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итүдән башка) (01.15.02);

элемтә белән идарә итү (03.04);

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә җайга салу (01.09);

социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01.1);

икътисадны мобилизацион әзерләү белән идарә итү (02.04);

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән юстиция өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.03);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.17);

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты белән туризм өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.09);

Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы белән дәүләти-хосусый партнерлык һәм хосусый инвестицияләр, инвестиция проектларын тормышка ашыруны комплекслы алып бару өлкәсендә инвестиция эшчәнлеген үстерү белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.10);

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.10);

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 73-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә Россия Федерациясе тарафыннан Россия Федерациясе субъектларына тапшырылган вәкаләтләрне үтәгәндә, мәдәният һәм тарихи-мәдәни мирас өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функциясен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы һәм мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функциясен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы белән;

Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасына бүлеп бирелгән федераль бюджет акчасын тоту буенча контроль чараларын

гамәлгә ашыру кысаларында финанс-бюджет өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функциясен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы, Россия Федерациясе Хисап палатасы белән.»;

3.3 пунктта:

3.3.21 пунктчада «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

3.3.41 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.41. Билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан республика башкарма хакимият органнарына идарә итү йөкләмәсе составында раслана торган республика башкарма хакимият органына беркетелгән Татарстан Республикасында халыкның тормыш сыйфатын, социаль-икътисадый хәлен һәм эшчәнлек төрләрен бәяләү индикаторлары күрсәткечләренә ирешүне тәэмин итә;»;

3.3.46 пунктчада «министрлыклар һәм ведомстволар» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

5.3 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин